СОВЕТ СТАРОЧУРИЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ЧҮРИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

ул. Новая, д.52, с. Старое Чурилино, Арский муниципальный район, 422014

Яңа урамы, 52 нче йорт, Иске Чүриле авылы, Арча муниципаль районы, 422014

Тел. (84366)57-3-48, 3-06-09 факс (84366)57-3-48, 3-06-09 E-mail: Schur.Ars@tatar.ru.

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

**КАРАРЫ**

**19 октябрь 2020 ел. N 6**

**Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге Иске Чүриле авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Иске Чүриле авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге Иске Чуриле авылында, Иске Чүриле авылы, Яңа урам, 52 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2020 елның 06 ноябренә 13 сәгать 00 минутта халык җыенының 1 нче этабын билгеләргә.

2. Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге Иске Чуриле авылында, Иске Чүриле авылы, Яңа урам, 52 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2020 елның 07 ноябренә 13 сәгать 00 минутта халык җыенының 2 нче этабын билгеләргә.

3. Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарырга.

1нче этап: Яңа, Яшел урамнарда яшәүчеләр.

2нче этап: Матросов, Мәктәп урамнарында яшәүчеләр.

4. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2021 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге Иске Чүриле территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Иске Чүриле авылы, Яшел ур., 63 нче йорттан Мәктәп ур., 82 нче йортка кадәр юлга вак таш җәю;

-Иске Чүриле авылы, Матросов ур., 2 нче йорттан Мәктәп ур., 85 нче йортта кадәр юлга вак таш җәю;

-Иске Чүриле авылы, Яңа ур., 5 нче йорттан 11 нче йортка кадәр юлга вак таш җәю;

- урам утларын ремонтлау, шул исәптән Яшел ур., 42 нче йорттан 56 нчы йортка кадәр светодиод лампалар сатып алу һәм кую;

- 1 данә янгын гидранты сатып алу һәм Матросов урамына урнаштыру;

- Матросов урамы, 2 нче йорттан Мәктәп урамы, 40 нчы йортка кадәр ерганакны киңәйтү һәм тирәнәйтү;

- Иске Чүриле авылында рөхсәтсез чүплекләр урнашкан урыннардагы җирләрне рекультивацияләү;

-МТЗ-82 тракторына 1 данә көчәйтелгән КУН сатып алу;

- МТЗ-82 тракторына 1 данә КРН 2.1 роторлы элмә чапкыч сатып алу.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

5. Арча муниципаль районы районы Иске Чүриле авыл җирлеге Иске Чүриле авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Иске Чүриле авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы Иске Чүриле авылы, Яңа урам, 52 йорт адресы буенча, ТР, Арча районы Иске Чүриле авылы, Мәктәп урам, 34 йорт адресы буенча,интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Иске Чүриле авыл җирлеге башлыгы Р.Т.Һидиятуллин